ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Габделхая Каримова, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Габделхәй Кәримов урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar. ru

**КАРАР**

**10 декабрь 2024 ел** **№30**

**Арча муниципаль районы "Шушмабаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Шушмабаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге уставы, "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2022 елның 04 августындагы 70 номерлы Шушмабаш авыл җирлеге Советы карары нигезендә, 13.11.2024 N8, 13.11.2024 N9, 13.11.2024 N10, 13.11.2024 N11, 14.11.2024г. N 12, 14.11.2024 N 13, 14.11.2024 №14 җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатыннан, Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы "Шушмабаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: ТР, Арча районы, Шушмабаш авылы, Габделхәй Кәримов ур., 1б, ТР, Арча районы, Носы авылы, Татарстан ур., 45 йорт.

3. "Шушмабаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында" 2023 елның 14 декабрендәге 47 номерлы Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны өстемә алам.

Шушмабаш авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе В.В.Сәгыйтов

Шушмабаш авыл җирлеге
башкарма комитетының
10 декабрь 2024 ел, №30
карарына кушымта

**Арча муниципаль районы "Шушмабаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Арча муниципаль районы "Шушмабаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын Арча муниципаль районы "Шушмабаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә нинди мөнәсәбәттә булуларына карамастан, 2024 елның 16 февраленә кадәр түлиләр.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары (бергә яшәүче ата-аналар, ир яки хатын, балигъ булган балалар).

4. Гражданнарның аерым категорияләре өчен:

а) көндезге бүлектә белем алучы студентлар,

б) 1 төркем инвалидлар,

в) 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен түләүләр күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

5. Нигезле сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының (ата-анасының, иренең/хатынының, балаларының) вафат булуы,

б) янгын яисә башка табигый бәла-казалар аркасында зыян килү гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне өч айдан да артмаган вакытка кичектерү бирелә.

6. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында гражданнарга хәбәр итү бланкы (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгару, Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру, шулай ук кул куеп тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләүнең тулы яисә киметелгән күләме, аны түләү срогы булырга тиеш.

7. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Арча муниципаль районы "Шушмабаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

8. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясарга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча акча күчерү юлы белән башкарыла.

9. Түләү фактын приход касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслый торган башка документлар раслый.

10. Гражданнарның үзара салым акчалары билгеләнгән вакытта кертелмәгәндә, алар законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Шушмабаш авыл җирлеге
башкарма комитетының
10 декабрь 2024 ел, №30_
карарына 2 нче кушымта

**Шушмабаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә N ______________**

Түләүченең Ф.И.А.и_______________________________________________

Адресы:____________________________________________________________

Нигезе_____________________________________________________

Сезгә ______________________ чараларны гамәлгә ашыруга бер тапкыр түләү_________________________________ суммада ____________ сум түләргә кирәк.

түбәндәге реквизитлар буенча:__________________________________________

алучының банкы БИК __________________________

Сч. N ____________________________________

Алучы Сч. N ____________________________

ИНН ________________________________________

КПП ________________________________________

КБК ________________ОКАТО ________________

Түләүнең билгеләнеше _________________________________________________

Җитәкче ________________ ____________________________________

М. у. (имза) (имзаның аңлатмасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисем сызыгы - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

"Шушмабаш авыл җирлеге"муниципаль берәмлегендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне түләү турында хәбәрнамә №__
суммада _______________ сум

Түләүченең Ф. и.а.и. ______________________________________________

Адресы: __________________________________________________________

Алдым "___" ______________ 20__ ел ___________________________________

(түләүченең имзасы /ФИАи)

Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, корешок тутырыла һәм Шушмабаш авыл җирлеге Башкарма комитетында кала